ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Красновидово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Красновидово авылы
тел. 8 (843 77) 2 04 13

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Красновидовского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Красновидово
тел. 8 (843 77) 2 04 13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 25 июле №11

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 мартындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының салым чыгымнары исемлеген төзү һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 мартындагы 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла».

1.2. 12 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына һәм (яисә) муниципаль программаларга карамый торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе».

1.3. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Красновидово
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Болтаков